ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

№ 1458

«2020 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасын раслау турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2008 елның 10 декабрендәге 799 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабреннән 1417 номерлы Татарстан Республикасы законы таләпләре белән һәм хезмәтне саклау өлкәсендә гражданнарның социаль-хезмәт хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2020 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасын раслау турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау Программасы исемендә «2020-2022» саннарын «2023-2025» саннарына алмаштырырга.

2. 2023 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасын (1 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе И.И.Шакиров

ТР Югары Ослан муниципаль
районы Башкарма комитетының
__________ ___________карарына
1 нче кушымта

# 2023-2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ХЕЗМӘТ ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ҺӘМ АНЫ САКЛАУ ПРОГРАММАСЫ

Исеме:
2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы.

Программаны эшләү өчен нигез:

2006 елның 30 июнендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чаралары турында» Россия Федерациясенең 1995 елның 26 августыннан 843 карары, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына бюджет процессын камилләштерүгә бәйле үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 07 июнендәге 104-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау Министрлыгының «Зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары белән эш иткән хезмәткәрләрне санатор-курорт дәвалавы һәм хезмәткәрләрнең производство травматизмын һәм һөнәри авыруларын киметү буенча кисәтү чараларын финанс белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 12 декабреннән № 580-н боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау Министрлыгының «Бөтенроссия хезмәт шартлары һәм аны саклау мониторингын үткәрү турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1197 номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2008 елның 10 октябрендәге 799 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары, «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 9 августыннан 553 карары, «Татарстан Республикасында хезмәт торышын һәм шартларын яхшырту чаралары турында» 2014 елның 10 октябрендәге 394 номерлы Министрлар Кабинеты карары.

Программаның максатлары:

Программаның төп максатлары түбәндәгеләр:
производство белән бәйле бәхетсезлек очракларын кисәтү һәм киметү; һөнәри куркынычларны ачыклау һәм киметү; эшкә сәләтлелекне вакытлыча югалтып һөнәри авырулар санын киметү; хезмәткәрләрне һөнәри куркынычтан хокукый һәм социаль яклау гарантияләре дәрәҗәсен күтәрү; һөнәри күнекмәләрне камилләштерү һәм

хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү; хезмәткәрләрнең куркыныч һәм зарарлы җитештерү факторларына йогынтысын бетерү хисабына хезмәт шартларын яхшырту.

Программаның бурычлары:

- хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру,
- җитештерү травматизмы, һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү, предприятиеләрдә һәм Югары Ослан муниципаль районы оешмаларында хезмәт шартларының һәм саклауның торышын яхшырту;
- эш бирүче тарафыннан сәламәт һәм имин хезмәт шартлары тудыруны тәэмин итә торган икътисадый һәм оештыру принципларын булдыру;
- уңайсыз хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын кыскарту;
- хезмәткәрләрнең хезмәт шартларына социаль якланганлыгын арттыру;
- хезмәтне саклауга, сәнәгать иминлегенә һәм хезмәт гигиенасына конституцион гарантияләр тәэмин итү.

Программаны гамәлгә ашыру сроклары:

2023 - 2025 еллар.

Финанслау чыганаклары: предприятиеләрнең, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның, Социаль иминият фондының бюджет акчалары

Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре:

Индикаторларның чик күрсәткечләренә ирешү:
- производстволарда зыян күрүчеләр саны эшләүчеләрнең 1000енә 0,2 дән артык түгел;
- җитештерү имгәнүләренә һәм имгәнүләргә бәйле рәвештә бер зыян күрүчегә хезмәткә сәләтсезлек көннәре саны 11,0 көн;
– хезмәт шартларында мәшгуль, санитар-гигиена нормаларына 20% ка кадәр җавап бирмәүче хезмәткәрләрнең чагыштырма саны.

2023 – 2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ХЕЗМӘТ ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ҺӘМ ХЕЗМӘТНЕ САКЛАУ ТЕРРИТОРИАЛЬ ПРОГРАММАСЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ЧАРАЛАРЫ

| т/б № | Чаралар | Җаваплы башкаручылар | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Хезмәт шартларын саклау һәм яхшырту буенча район Координация советы утырышында 2023-2025 елларга хезмәт шартларын саклау һәм яхшырту буенча территориаль программаны эшләргә һәм расларга. | Координацион совет секретаре | 2022 елның декабре |
| 2 | Һөнәр берлекләре комитетлары һәм оешмалар администрациясе белән берлектә, 2023-2025 елларга күмәк шартнамәләр кабул итү чорында хезмәтне саклау буенча чаралар, хезмәт шартларын махсус бәяләүне, махсус кием һәм аяк киеме, СИЗ, махсус туклану, медицина тикшерүе, эшләүче хезмәткәрләрне савыктыру һәм ял итү, һөнәри куркынычларны киметү һ.б. турында фикер алышу һәм килештерү. | Координацион совет әгъзалары, тармак профсоюз комитетлары | Коллектив килешүләр вакыты чыккан саен |
| 3 | Координацион совет утырышында, җитәкчеләрне тыңлау белән, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрдә хезмәт шартларын махсус бәяләүнең колачлануы һәм срокларын анализларга. | Кеше хокуклары буенча вәкил һәм профсоюзлар белән берлектә ОТ буенча Координация советы. | Һәр оешма буенча 5 еллык срок тәмамлангач, индивидуаль рәвештә |
| 4 | Хезмәт һәм ял лагерьларын, мәктәп яны лагерьларын җәйге чорда хезмәт саклау таләпләрен үтәү, хезмәтне саклау таләпләрен үтәү һәм Координация советында нәтиҗәләрне тыңлап, санитария-гигиена таләпләренә туры килү буенча тикшерүләрне оештырырга. | Мәгариф бүлеге, Башкарма комитет вәкиле, Роспотребнадзор бүлеге, хезмәтне саклау буенча белгеч | Июнь-июль 2023-2025 еллар. |
| 5 | Район оешмаларында һәм предприятиеләрендә производствода имгәнүләр һәм бәхетсезлек очракларына анализ ясарга. | Башкарма комитет | ел саен кварталга 2 предприятие |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Югары Ослан районы предприятие һәм оешма җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтне саклау буенча укуын республика методик үзәгеннән һәм укыту хокукына лицензиясе булган оешмалардан укытучылар чакырып оештырырга | Башкарма комитет | Кирәк булган саен 2023-2025 еллар дәвамында. |
| 7 | Район оешмаларын һәм предприятиеләрен хезмәтне саклау һәм иминлек техникасы буенча методик пособиеләр, янгын-техник минимумы белән тәэмин итәргә. | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, хезмәтне саклау буенча белгеч | Ел саен |
| 8 | «Хезмәтне саклау буенча районның иң яхшы предприятиесенә смотр-конкурс үткәрү нигезләмәсен»эшләргә һәм барлык предприятиеләргә һәм оешмаларга җиткерергә. | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Башкарма комитет, Координация советы | 2023-2025 еллар 1 кварталы |
| 9 | Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган хезмәтне саклау айлыгы үткәрү | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Башкарма комитет, Координация советы | 01 апрельдән 2023-2025 еллар. |
| 10 | Хезмәтне саклау буенча Координация советы утырышында җитәкчеләрне тыңлап, авыр нәтиҗәләр белән (үлемгә китерүче һәм массакүләм очракларга) җитештерү травматизмының һәр очрагын тикшерүдә катнашырга, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар эшләү һәм хокук бозучыларга карата чаралар күрү . | Координация советы, хезмәтне саклау буенча белгеч | Кирәк булганда |
| 11 | Зарарлы һәм куркыныч матдәләр белән контактта эшләүче затларга профилактик медицина тикшерүләре уздыруны оештырырга.<br>Эшкә кергәндә медицина тикшерүен үткәрүне тикшереп торуны гамәлгә ашырырга. | «Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, предприятие, оешма, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре. | График буенча |
| 12 | Санитария-көнкүреш шартларына, хезмәтне саклауның торышына анализ ясарга, районның агросәнәгать предприятиеләрендә шәхси яклау һәм махсус киемнәр | Хуҗалыклар җитәкчеләре, УСХиП, Координация советы | 2023-2025 елның II һәм IV кварталы. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | белән тәэмин итү, Координация советында җитәкчеләрне чакырып тикшерү нәтиҗәләрен тыңларга. | | |
| 13 | Югары Ослан муниципаль районының төзелеш мәйданчыкларында шәхси саклау чараларын куллану буенча ел саен рейдлар үткәрү | Хезмәтне саклау буенча координация советы әгъзалары, | 2023-2025 елның май-июлендә |
| 14 | Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыклары, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау Министрлыгы, профсоюзлар үткәргән киңәшмәләрдә, семинарларда, хезмәтне саклау буенча укуларда, СОУТ һ.б.ларда катнашырга. | Хезмәтне саклау буенча Координация советы әгъзалары, хезмәтне саклау буенча белгечләр, җитәкчеләр | 2023-2025 ел дәвамында ел саен уздырыла торган графиклар нигезендә |
| 15 | «Волжская Новь» район газетасы, Башкарма комитет сайты аша хезмәт шартларын яхшырту һәм саклау буенча уңай эш тәҗрибәсен пропагандалауны оештырырга | Координация советы, «Волжская Новь» газетасы редакциясе | Ел дәвамында |
| 16. | Социаль иминият фонды белән берлектә зарарлы һәм (яки) куркыныч производство факторлары белән бәйле производство травматизмын һәм профессиональ авыруларны кисәтү чараларын өстәмә финанслау эшен башкарырга. | Координация советы | Ел саен, 1 августка кадәр |

Эшләр белән идарә итүче А.К. Минһаҗева